КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 август г.Казань № 650

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км – 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 декабрь, б-2668 нче; 2023 ел, 8 декабрь, б-2800 нче боерыклары, 2022 елның 11 гыйнварындагы КС-17/98 номерлы концессия килешүе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Автострада» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасы Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км – 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен «КИЧУЧАТ» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлекләренең хокук иясе) милкендә һәм арендасында булган, 1 нче кушымтада күрсәтелгән, 30 350 454,75 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган 65 695 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. 2 нче кушымтада күрсәтелгән, җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләренең хокук иясенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Автострада» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында һәм арендалау гамәлдән чыгу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләренең хокук иясенә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләренең хокук иясе тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. «Автострада» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км – 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1262 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләү күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 13 август, 650 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Җир кишәрлегенең гомуми мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Хокук иясе | Шәхси сервитут (теркәү датасы, хокук иясе) |
|---|---|---|---|---|---|
| 16:07:000000:800 | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы | 21 559 350,95 | 49 903 | «КИЧУЧУЧАТ» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте (милекче), ИНН: 1644012617 | 10.11.2023, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:07:000000:811 | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы | 7 966 383,8 | 9 945 | «КИЧУЧУЧАТ» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте (милекче), ИНН: 1644012617 | 05.03.2021, «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыяте |
| 16:07:000000:1899 | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы | 824 720 | 5 847 | «КИЧУЧУЧАТ» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте (арендатор), ИНН: 1644012617 | - |
| Барлыгы | | 30 350 454,75 | 65 695 | | |

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 13 август, 650 нче карарына 2 нче кушымта

Алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 16:07:000000:800 | 16:00:000000:1058 | «Әлмәт шәһәренең БС-273 линиясе-кабельле элемтә корылмасы - 21 нче муфта» |
| | 16:00:000000:1457 | «Төгәлләнмәгән төзелеш объекты» |
| | 16:00:000000:1524 | «Шешма» УКПН нан алып «Шешма - Кәләй» ПСПына кадәр Напорный нефть үткәргече» |
| | 16:00:000000:1592 | «ВОЛС элемтә линиясе» |
| | 16:00:000000:242 | «Әлмәт - Горький-2 магистраль нефть үткәргече, d = 820 мм, участок 0 - 65 км» |
| | 16:00:000000:281 | «Әлмәт - Горький-3 магистраль нефть үткәргече, d = 1020мм, участок 0 - 58 км» |
| | 16:07:000000:7876 | «6 нчы ноктадан Миннебай күкерт чистарту җайланмасына кадәр полиэтилен торбалардан газ үткәрү торбалары ПЭ 100 ГАЗ SDR11-400 × 36,3 мм» |
| | 16:07:130006:3653 | «Тимер-бетон терәкләрдәге җитештерү өчен 35 КВ ЮВЭҮЛ» |
| | 0:0:0:889 | «Мешиха – Әлмәт участогында элемтә линия-кабель корылмасы – җепселле-оптик тапшыру линиясе» |
| | 0:0:0:1343 | «Линия корылмасы – Әлмәт – Мешиха кабель элемтә линиясе, Әлмәт челтәрләр белән идарә итү системасы – 6/4 нче хезмәт күрсәтелми торган пункт» |
| | 16:07:290006:340 | «6927 номерлы скважина» |
| | 16:07:290006:339 | «6926 номерлы скважина» |
| | 16:07:290006:338 | «6928 номерлы скважина» |
| | 16:07:330002:953 | «2952Г номерлы скважина» |
| | 16:07:290006:343 | «6925 номерлы скважина» |
| | 16:07:290006:342 | «6924 номерлы скважина» |
| | 16:07:290006:344 | «6923 номерлы скважина» |
| 16:07:000000:811 | 16:00:000000:1058 | «Әлмәт шәһәренең БС-273 линиясе-кабельле элемтә корылмасы - 21 нче муфта» |
| | 16:00:000000:1457 | «Төгәлләнмәгән төзелеш объекты» |
| | 16:00:000000:1524 | «Шешма» УКПН нан алып «Шешма - Кәләй» ПСПына кадәр Напорный нефть үткәргече» |
| | 16:00:000000:1592 | «ВОЛС элемтә линиясе» |
| | 16:00:000000:242 | «Әлмәт - Горький-2 магистраль нефть үткәргече, d = 820 мм, участок 0 - 65 км» |
| | 16:00:000000:281 | «Әлмәт - Горький-3 магистраль нефть үткәргече, d = 1020мм, участок 0 - 58 км» |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | 16:07:000000:7876 | «6 нчы ноктадан Миннебай күкерт чистарту җайланмасына кадәр полиэтилен торбалардан газ үткәрү торбалары ПЭ 100 ГАЗ SDR11-400 × 36,3 мм» |
| | 16:07:330001:2051 | «Чәчелүче материаллар  склады бинасы» |
| | 16:07:130006:3653 | «Тимер-бетон терәкләрдәге җитештерү өчен 35 КВ ЮВЭҮЛ» |
| | 0:0:0:889 | «Мешиха – Әлмәт участогында элемтә линия-кабель корылмасы – җепселле-оптик тапшыру линиясе» |
| | 0:0:0:1343 | «Линия корылмасы – Әлмәт – Мешиха кабель элемтә линиясе, Әлмәт челтәрләр белән идарә итү системасы – 6/4 нче хезмәт күрсәтелми торган пункт» |
| | 16:07:000000:8910 | «6 нчы ноктадан Миннебай күкерт чистарту җайланмасына кадәр полиэтилен торбалардан газ үткәрү торбалары ПЭ 100 ГАЗ SDR11-400 × 36,3 мм» |
| 16:07:000000:1899 | 16:00:000000:1524 | «Шешма» УКПН нан алып «Шешма - Кәләй» ПСПына кадәр Напорный нефть үткәргече» |
| | 16:00:000000:1592 | «ВОЛС элемтә линиясе» |
| | 16:00:000000:242 | «Әлмәт - Горький-2 магистраль нефть үткәргече, d = 820 мм, участок 0 - 65 км» |
| | 16:00:000000:281 | «Әлмәт - Горький-3 магистраль нефть үткәргече, d = 1020мм, участок 0 - 58 км» |
| | 16:07:000000:7876 | «6 нчы ноктадан Миннебай күкерт чистарту җайланмасына кадәр полиэтилен торбалардан газ үткәрү торбалары ПЭ 100 ГАЗ SDR11-400 × 36,3 мм» |
| | 16:07:000000:8126 | «Әлмәт - Чупаево» - Кичүчат” автомобиль юлы |
| | 16:07:330001:2050 | «Зерносушилка СЗШ-16» |
| | 16:07:330001:2054 | «Электр җиһазларын ремонтлау остаханәсе бинасы» |
| | 16:07:330001:2051 | «Симертү бинасы» |
| | 16:07:330001:2052 | «Административ бина» |
| | 16:07:000000:8632 | «Сөт эшкәртү комплексы бинасы» |
| | 16:07:330001:2051 | «Чәчелүче материаллар  склады бинасы» |
| | 16:07:130006:3653 | «Тимер-бетон терәкләрдәге җитештерү өчен 35 КВ ЮВЭҮЛ» |
| | 0:0:0:889 | «Мешиха – Әлмәт участогында элемтә линия-кабель корылмасы – җепселле-оптик тапшыру линиясе» |
| | 0:0:0:1343 | «Линия корылмасы – Әлмәт – Мешиха кабель элемтә линиясе, Әлмәт челтәрләр белән идарә итү системасы – 6/4 нче хезмәт күрсәтелми торган пункт» |

_______________